## *УМК «Татарча да яхшы бел» для русскоязычных учащихся 5-11 классов*

учебник
рабочая тетрадь
аудиодиск
сборник КИМ
методическое пособие для учителя
электронный учебник











# Комплект для 5 класса















# Творческий коллектив – создатели УМК

Руководитель проекта Шайхелисламов Раис Фалихович

Автор Нигматуллина Рузалия Рахметовна








**Соавторы**

Фаизова Фирая Сафовна Яковлева Венера Алексеевна



## Учителя -помощники

Аминова Аниса Анваровна,
Султанова Румия Миргазияновна
Юнусова Рушания Абударовна

Редактор **Раскулова Роза Ивановна**

Художники **Алла Айсена и Валерий Фомин**



композитор **Ахметшин Васим Василович**

диктор **Ахметшина Асия Мухаметовна**

звукорежиссёр **Ахметшин Айдар Васимович**






# Фотографы

**Радик Габдрахманов**

**Вячеслав Бурнышев**






# Работа с героями учебника







# Форзац учебника

**Исемнәрнең килешләрдә төрләнеше**
(Склонение имён существительных по падежам)

| Килешләр (Падежи) | Килеш сораулары (Падежные вопросы) | Аффикслар (Аффиксы, окончания) |
|---|---|---|
| Баш килеш (Именительный п.) | Кем? (Кто?) Нәрсә? (Что?) | — |
| Иялек килеше (Притяжательный п.) | Кемнең? (Кого? Чей?) Нәрсәнең? (Чего?) | -ның/-нең |
| Юнәлеш килеше (Направительный п.) | Кая? (Куда?) Кемгә? (Кому?) Нәрсәгә? (Чему?) | -га/-гә -ка/-кә |
| Төшем килеше (Винительный п.) | Кемне? (Кого?) Нәрсәне? (Что?) | -ны/-не |
| Чыгыш килеше (Исходный п.) | Кайдан? Каян? (Откуда?) Кемнән? (От кого?) [illegible] | [illegible] |
| Урын-вакыт килеше (Местно-времен[illegible] | [illegible] | [illegible] |

**Зат алмашлыкларының килешләрдә төрләнеше**
(Склонение личных местоимений по падежам)

| | | | |
|---|---|---|---|
| Б. к. (Кем?) | мин (я) | син (ты) | ул (он, она, оно) |
| И. к. (Кемнең?) | минем (у меня, мой, моя, моё, мои) | синең (у тебя, твой, твоя, твоё, твои) | аның (у него, у неё, его, её) |
| Ю. к. (Кемгә?) | миңа (мне) | сиңа (тебе) | аңа (ему, ей) |
| Т. к. (Кемне?) | мине (меня) | сине (тебя) | аны (его, её) |
| Ч. к. (Кемнән?) | миннән (от меня, из меня, с меня) | синнән (от тебя, из тебя, с тебя) | аннан (от него, от неё; из него, из неё; с него, с неё) |
| У.-в. к. (Кемдә?) | миндә (у меня, во мне, на мне) | синдә (у тебя, в тебе, на тебе) | анда (у него, у неё; в нём, в ней; на нём, на ней; там) |
| Б. к. (Кем?) | без (мы) | сез (вы) | алар (они) |
| И. к. (Кемнең?) | безнең (у нас, наш, наша, наше, наши) | сезнең (у вас, ваш, ваша, ваше, ваши) | аларның (у них, их) |
| Ю. к. (Кемгә?) | безгә (нам) | сезгә (вам) | аларга (им) |
| Т. к. (Кемне?) | безне (нас) | сезне (вас) | аларны (их) |
| Ч. к. (Кемнән?) | бездән (от нас, с нас, из нас) | сездән (от вас, с вас, из вас) | алардан (от них, с них, из них) |
| У.-в. к. (Кемдә?) | бездә (у нас, в нас, на нас) | сездә (у вас, в вас, на вас) | аларда (у них, в них, на них) |

**Тартымлы исемнәрнең килешләрдә төрләнеше**
(Склонение имён существительных с аффиксами принадлежности по падежам)

| | Берлек сан | | | Күплек сан | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Килешләр | минем ... | синең ... | аның ... | безнең ... | сезнең ... | аларның ... |
| Б. к. | -ым/-ем, -м | -ың/-ең, -ң | -ы/-е, -сы/-се | -быз/-без -ыбыз/-ебез | -гыз/-гез -ыгыз/-егез | -лары/-ләре |
| И. к. | -ның/-нең | -ның/-нең | -ның/-нең | -ның/-нең | -ның/-нең | -ның/-нең |
| Ю. к. | -а/-ә | -а/-ә | -(н)а/-(н)ә | -га/-гә | -га/-гә | -(н)а/-(н)ә |
| Т. к. | -ны/-не | -ны/-не | -н | -ны/-не | -ны/-не | -н |
| Ч. к. | -нан/-нән | -нан/-нән | -(н)нан/ -(н)нән | -дан/-дән | -дан/-дән | -(н)нан/ -(н)нән |
| У.-в. к. | -да/-дә | -да/-дә | -(н)да/-(н)дә | -да/-дә | -да/-дә | -(н)да/-(н)дә |

**Сан**
(Имя числительное)

| [illegible]ан төркемчәләре (Виды [illegible]ислительных) | Сораулар (Вопросы) | Ясалыш ысулы (Способ образования) | Мисаллар (Примеры) |
|---|---|---|---|
| [illegible]икъдар саны [illegible]ичественные [illegible]тельные) | Ничә? Күпме? (Сколько?) | — | бер (один), ун (десять) ике йөз унбер (двести одиннадцать) |
| [illegible]тип саны [illegible]ковые [illegible]ельные) | Ничәнче? (Какой по счёту/ по порядку?) | После гласных: -нчы/-нче После согласных: -ынчы/-енче | алты+нчы (шестой) ике+нче (второй) ун+ынчы (десятый) йөз+енче (сотый) |
| [illegible] саны [illegible]льные [illegible]ные) | Ничәү? (Сколько?) | -ау/-әү | ун+ау (десятеро) биш+әү (пятеро) |
| [illegible]ы [illegible]ьные [illegible]ые) | Ничәшәр? (По сколько?) | После гласных: -шар/-шәр После согласных: -ар/-әр | алты+шар (по шесть) ике+шәр (по два) тугыз+ар (по десять) бер+әр (по одному) |
| [illegible]ьные | Ничәләп? (Приблизительно сколько?) | -лап/-ләп -ларча/-ләрчә -лаган/-ләгән -нарча/-нәрчә | егерме+ләп (около 20) йөз+ләрчә мең+ләгән миллион+нарча |

## Шартлы билгеләр

Фонетик күнегү

Тыңлагыз

Укыгыз

Сорауларга җавап бирегез

Парлап эшләгез

Искә төшерегез
Кабатлагыз

Рәсемгә карагыз

Истә калдырыгыз
Дөрес әйтегез

Төзәтегез

Сүзлекчә

Сөйләм этикасы

Бу бик кызык



## Эчтәлек

1 Сагынырбыз сине, җәй! .................................. 5
2 Ә мәктәптә күңеллерәк .................................. 35
3 Тел кешене дус итә .................................. 49
4 Гаиләмне бик яратам .................................. 64
5 Мин әтиемә дә, әниемә дә охшаган ............... 78
6 Фатирыбыз миңа ошый .................................. 95

# СҮЗЛЕК

### А
**авáз** — звук
**аеры́м** — отдельно
**акланыргá** — оправдываться
**акы́л** — ум
**алдаларгá** — обманывать
**алыргá** — 1. вычитать; 2. брать
**аңларгá** — понимать
**арттырыргá** — увеличивать
**аяк өсте** — стоя на ногах

### Ә
**әдәбия́т** — литература
**әдә́п** — вежливость
**әзерләргә́** — готовить
**әйләнергә́** — 1. превратиться; 2. вращаться, крутиться
**әләкләргә́** — ябедничать
**әләкче́** — ябеда
**әлбә́ттә** — конечно
**әрчергә́** — чистить

### Б
**бáрыбер** — всё равно
**бәйлә́м** — 1. связка; 2. букет
**бәйләргә́** — вязать
**бәке́** — прорубь
**бәрергә́** — ударять, стукнуть
**бәрелешергә́** — сталкиваться
**бәс** — иней
**бәхә́с** — спор
**бәхәсләшергә́** — спорить
**бәхе́т** — счастье
**бәя́** — цена, стоимость
**бергә́** — вместе
**бердә́нбер** — единственный
**бéркатлы** — 1. простоватый, наивный; 2. бесхитростный
**бéртуган** — родной
**бéрүзем** — (я) один
**бéрьюлы** — одновременно
**бишé**к — колыбель
**бө́тен** — весь
**бөтенлә́й** — 1. полностью; 2. совсем
**буй** — рост
**булыргá** — быть
**буш** — пустой, пусто
**бушкá** — 1. зря, впустую; 2. бесплатно
**быéл** — в этом году

### В
**валчы́к** — крошка

### Г
**гадә́т** — привычка
**гадәти́** — обыкновенный, обычный
**гадәтләнергә́** — привыкать
**гадәттә́** — обычно, как правило
**газиз** — родной
**гайбә́т** — сплетня
**гайбәтче́** — сплетник
**гасы́р** — век
**гому́мән** — в общем, в целом
**гомуми́** — общий

### Д
**давы́л** — буря
**дәвáм** — продолжение
**дәвáм итәргә** — продолжить
**дәүлә́т** — государство
**диңгé**з — море
**дөнья́** — мир, вселенная
**дөя** — верблюд

### Җ
**җәлләргә́** — жалеть
**җавáп** — ответ
**җан** — душа
**җәяргә́** — 1. стелить; 2. рас...
**җәя́ү** — пешком
**җепшé**к — талый
**җил** — ветер
**җилләтергә́** — проветриват...
**җиңәргә́** — побеждать
**җиңé**л — лёгкий, легко
**җитәкче́** — руководитель

### И
**игезәклә́р** — двойняшки,
**игелекле́** — добрый
**игътибáр** — внимание



## Биремнәрнең тәрҗемәсе / Перевод заданий

| Биремнәрнең тәрҗемәсе | Перевод заданий |
|---|---|
| **аерманы әйтегез** | скажите разницу |
| **бирелгән үрнәк буенча үзгәртегез** | измените по данному образцу |
| **бу җөмләләр белән килешәсезме?** | согласны ли с этими предложениями? |
| **бер-берегезгә сораулар бирегез** | задайте друг другу вопросы |
| **дөрес кулланыгыз** | используйте правильно |
| **дөрес җавапларны табыгыз** | найдите правильные ответы |
| **диктор артыннан кабатлагыз** | повторите за диктором |
| **җөмләләр текстның эчтәлегенә туры киләме?** | соответствуют ли предложения содержанию текста? |
| **җөмләләрне тәмамлагыз** | закончите предложения |
| **искә төшерегез** | вспомните |
| **истә калдырыгыз** | запомните |
| **кагыйдәне искә төшерегез** | вспомните правило |
| **кирәкле кушымчалар белән әйтегез** | скажите с нужными окончаниями |
| **кулланыгыз** | используйте |
| **нокталар урынына ... куегыз** | поставьте вместо точек ... |
| **парлап эшләгез** | работайте в парах |
| **рәсемгә карап сөйләгез** | расскажите по рисунку |
| **сорауларга җавап бирегез** | ответьте на вопросы |
| **сүзлектән карагыз** | посмотрите по словарю |
| **сорашыгыз** | расспросите |
| **сәнгатьле укыгыз** | читайте выразительно |
| **текстка исем бирегез** | озаглавьте текст |
| **текстның төп фикерен әйтегез** | скажите основную мысль текста |
| **төзәтегез** | исправьте |
| **үз фикерегезне әйтегез** | скажите своё мнение |
| **яңа структура белән танышыгыз** | познакомьтесь с новой структурой |

# Внутреннее оформление


















Мәктәп түрендә — мәктәп формасы


Яңа укучы булу рәхәт түгел





# Вакытның кадерен беләм

## 9

### Беренче, икенче дәресләр

**Әйтегез әле, вакыт күпме?**



Иртәнге сәгать 8. Кичке сәгать 8. Көндезге сәгать 12. Төнге сәгать 12.

**1.** Истә калдырыгыз. Дөрес әйтегез.

| |
|---|
| **Сәгать ничә?** — Который час?<br>**Вакыт күпме?** — Сколько времени?<br>**Сәгать ничәдә?** — Во сколько часов? / В котором часу? |

**2.** Рәсемнәргә карагыз. Сәгать ничә? Дөрес әйтегез.

**3.** Сүзләрне тыңлагыз. Дөрес укыгыз.

иртәнге [и р т ә ң г ә́]
төнге [т ө ң г ө́]
әнкәй [ә ң к ә́ й]
борынгы [б о р о ң гъ ы́]

соңрак [с о ң о р а́ къ]
озаграк [о з а° г ы р а́ къ]
күбрәк [к ү б ә р ә́ к]
шаянрак [ш а° й а° н ы р а́ къ]

**4.** Рәсемнәргә карагыз. Үрнәктән файдаланып әйтегез.

Үрнәк: *Сәгать ничәдә? Иртәнге сәгать сигездә. Кичке ...*



**5.** Татарча әйтегез.

в 5 часов утра, в 10 часов дня, в 6 часов вечера, в 11 часов ночи, в 11 часов дня

**6.** Тыңлагыз. Эш дәфтәрендә вакытны дөрес күрсәтегез.

**7.** Рәсемнәргә карагыз. Лилиянең көн режимын сөйләгез.

Ул нишли? Йокыдан кайчан тора? Сәгать ничәдә ашый? ...



Йокыдан тора. Зарядка ясый. Юына. Сөртенә. Киенә. Иртәнге аш ашый.



Мәктәпкә бара. Тәнәфестә ашханәдә ашый. Мәктәптән кайта.



Көндезге аш ашый. Өйдә булыша. Урамда саф һавада йөри. Дәрес әзерли.



**5.** Дөрес әйтегез.

| | |
|---|---|
| **бер төстәге** — одного цвета | **бер төрдәге** — одного вида / фасона |
| **бертөсле** — одинаковый | **бертөрле** — одинаковый |

**6.** Татарча әйтегез.

пиджак одного цвета
рубашка светлого цвета
одежда одного фасона
брюки тёмного цвета

одинаковые галстуки
юбки средней длины
обувь на низком каблуке
туфли на высоких каблуках

**7.** Инглиз гимназиясендәге мәктәп формасы турында сөйләгез. Ул нинди булырга / булмаска тиеш?

**8.** Сөйләгез. Бу мәктәптә укучыларның чәчләре нинди булырга / булмаска тиеш?

**9.** Җөмләләрне тәмамлагыз.

Әгәр укучылар дәресләргә мәктәп формасында йөрсәләр:
- алар арасында бер-берсеннән көнләшү хисе булмый, чөнки...
- алар үз мәктәпләре белән горурлана, чөнки...
- алар зәвык белән киенергә өйрәнә, чөнки...
- алар дәресләрдә җитди эш белән шөгыльләнә, чөнки...

**10.** Сөйләгез. Мәктәп администрациясе ни өчен мәҗбүри мәктәп формасы керткән?

**11.** Истә калдырыгыз. Чәч турында шулай әйтәләр.



| |
|---|
| **тузгыган чәч** — растрёпанные волосы |
| **таралган чәч** — причёсанные волосы |
| **кистерелгән чәч** — подстриженные волосы |
| **җыйнак чәч** — аккуратные волосы |
| **җиткән чәч** — обросшие волосы *(о мальчиках)* |
| **җыелган чәч** — собранные *(длинные)* волосы |

**12.** 11 нче күнегүдәге сүзләрнең антоним вариантларын әйтегез.

**13.** Сөйләгез. Инглиз гимназиясендә укучыларның чәчләре нинди булырга / булмаска тиеш? Ә сезнең мәктәбегездә?





**14.** Рәсемнәргә карагыз. Укучыларның киемнәре турында фикерләрегезне әйтегез.

**15.** Искә төшерегез.

**шакмаклы** — в клетку
**буй-буй** — в полоску
**бөрчекле** — в горошек
**бизәкле** — с узорами

**кесәле** — с карманом
**төймәле** — с пуговицами
**якалы** — с воротником
**җиңле** — с рукавами

**16.** 23 нче һәм 24 нче биттәге рәсемнәргә карап, укучыларның мәктәп формасы турында сөйләгез.



Башлангыч класс укучылары һәм урта яшьтәге балалар нинди төстәге, нинди фасондагы кием сайлаганнар?

Бер үк класс укучыларының мәктәп формасы нинди детальләре белән аерылып тора?

# Рабочие тетради (5-11 классы)






## 13 нче тема

### Беренче, икенче, өченче дәресләр

1. Җөмләләрне татарча языгыз.

Посмотрите на моё платье, оно такое красивое.— ______________________________

Посмотрите в мои глаза, они такие радостные.— ______________________________

Посмотрите на моё лицо, оно такое счастливое.— ______________________________

2. Җөмләләрне укыгыз, кирәкле килеш кушымчаларын языгыз.

Кая?

Мәктәп бакчасы ________ барыгыз. Спорт түгәрәге ____________ йөрегез.
Ял бүлмәсе ______________ узыгыз. Белем бәйрәме _______ рәхим итегез.
Шәһәр китапханәсе ______ керегез. Татар теле кабинеты ________ үтегез.

3. Кирәкле зат алмашлыкларын языгыз, аффиксларны күрсәтегез.

___________ чакырсам, чакырмасам
___________ килсәң, килмәсәң
___________ шатланса, шатланмаса
___________ кайтсак, кайтмасак
___________ шылтыратсагыз, шылтыратмасагыз
___________ тәбрик итсәләр, тәбрик итмәсәләр

4. Фигыльләр уйлап, аларны кирәкле зат алмашлыклары белән языгыз.

___________сәм ___________саң
___________мәсәм ___________мәсәң

### «Әтәч нигә кычкыра?» мюзиклыннан

*Зөләйха Минһаҗева сүзләре,*
*Вәсим Әхмәтшин көе*

#### Бер, ике, өч

*(Чебиләр зарядкасы)*

(Марш)

1. Бер, ике, өч! — Балалар,
Шулай канат кагалар.
Бер, ике, өч! — Атлагыз,
Әйдәгез, сынатмагыз.

2. Утырыгыз, басыгыз.
Ялкаулана кайсыгыз?
Бер, ике, өч! — Бик әйбәт,
Хәрәкәттә бәрәкәт.

Бергә: Бер, ике, өч! — Атлагыз,
Әйдәгез, сынатмагыз.

#### Кояшта җылынабыз

*(Чебиләр җыры)*

1. Кояшта җылынабыз,
Яңгырда коенабыз.
Үләндәге чык белән

3. Без — сап-сары чебиләр,
Кояш бәбиләре без.
«Чеп-чеп» диеп йөрербез,
ргә өйрәнербез.

ә шундый чебидән
ър тавык, әтәчләр.
дә шундый гайрәтле,
ә кызыл кәпәчләр.

## 15 нче тема

1. Бу исем кайсы килештә?

Әдәпле бала транспортта **урынын** олыларга бирә.
а) чыгыш килешендә; б) юнәлеш килешендә; в) төшем килешендә

2. Җөмләне язып бетерегез.

Ринат трамвайда күзләрен йомып бара, чөнки ______________________________

а) ул йоклый; б) ул бик арыган; в) ул әбиләргә урынын бирергә теләми

3. Сүзнең дөрес тәрҗемәсен табып языгыз.

мешать — ______________________
а) көлергә; б) карарга; в) комачауларга

4. Җөмләне язып бетерегез.

Апам шигырь ятлый, шуңа күрә аңа ______________________________
а) комачауларга ярамый; б) комачауларга тиеш түгел; в) комачауларга кирәк

5. Сүзне татарча языгыз.

Менә ничә көн инде (беспрерывно)______________________ яңгыр яуды.
а) туктамый; б) бертуктаусыз; в) туктап

6. Фигыльне дөрес сайлагыз.

Яңгыр яумаса, аяк асты пычрак ______________________
а) булыр; б) була; в) булмас

7. Кирәкле сүзтезмәне сайлап языгыз.

Әдәпле бала мәктәптә ______________________________ исәнләшә.
а) класс җитәкчесе белән генә
б) үз укытучылары белән генә
в) бөтен укытучылар белән дә



## Күңелле ял итәбез

### Ребуслар

#### Сагынырбыз сине, җәй!



ШИГЪРИ БИРЕМ...

1. Кирәкле сүзләрне һәм кушымчаларны языгыз.

## Мәктәпкә килдек

________ җитте,
Мәктәп____ килдек,
Якын дуслар______
Яңадан күр______.

________ сез булган
Мәктәбебез____,
Хәзер бик рәхәт
Бөтенебезгә.

2. Кирәкле кушымчаларны языгыз.

## Без тырышлар

Укырга килдек мәктәпкә:
Укый______да сөйли______;
Барыбыз да бик тырышлар,
Ялкаулыкны сөймибез.

Җырлыйбыз да, би...
Чит телләр өйрән_...
Күп фәннәрне яхш...
Галимгә әйләнәбе...

Әйбәт билгеләр алабыз,
Эти________ шатлансыннар.
«Син акыллым, уңганым»,— ди...
Әни______ макта________.

3. Юлларын кирәкле тәртиптә урнаштырып, шигырьне язы...

## Кирлемән

Кирлемән киреләнә,
Гел кирегә сөйләнә.
Шәвәли һәм балалар
Мәктәпкә шат баралар;
Сагына ямьле җәйне,
Хуш исле чәчәкләрне,

«Артык у...
«Болай да...
Аның ук...
Аңа кан...
Яңа ду...
«4»ле,...

# Күңелле ял итәбез

## Ребуслар

### Сагынырбыз сине, җәй!



# Сборники КИМ (5-11 классы)






# ТЕСТЛАР

## 1. Кереш контроль тест

**А-1.** Туры килгән алмашлыкларны күрсәтегез.

| | |
|---|---|
| ______ җавабыгыз | 1) минем |
| ______ йортың | 2) синең |
| ______ дусларыбыз | 3) аның |
| ______ оныгы | 4) безнең |
| ______ киңәшем | 5) сезнең |
| ______ күршеләре | 6) аларның |

**А-2.** Исемнәрне кирәкле формада языгыз.

кунак — минем куна(к)______ әни — аның______
өй — синең ______ сәгать — безнең______
песи — аның ______ мәктәп — сезнең______

**А-3.** Артык сүзне табыгыз.

яңгыр, көз, саргая, пычрак, салкын, песи, җил

**А-4.** Татарча язып бетерегез.

Как дела? — Хәлләр ______?
Добрый день! — Хәерле______!
Спокойной ночи! — Тыныч______!

## 6. Йомгаклау тесты

**А-1.** *ә, е, ө* хәрефләрен сайлап, сүзләрне дөрес языгыз.

м__н__с__б__т, м__ст__кыйль, матд__, __д__би, үс__мл__к

**А-2.** Кайсы җөмлә сораугa җавап була алмый?

Бу уку елында сезнең классыгызда үзгәрешләр булдымы?

а) Әйе, безнең класска ике яңа укучы килде.
б) Әйе, безнең класста барысы да элеккечә, үзгәрешләр юк.
в) Әйе, безнең классның өч укучысы башка мәктәпкә күчте.

**А-3.** Парлы исемнәр ясагыз, тәрҗемәсен күрсәтегез.

| | | |
|---|---|---|
| а) тимер | ______ чар | ______ птицы |
| б) төс | ______ корт | ______ железо |
| в) чүп | ______ кыяфәт | ______ внешность |
| г) кош | ______ ярак | ______ мусор |
| д) кирәк | ______ томыр | ______ необходимость |

**А-4.** Кирәкле кушымчаларны сайлап, сыйфатлар ясап языгыз.

-лы/-ле ______, ______
-чан/-чән ______, ______
-чыл/-чел ______, ______

Сүзләр: *әдәп, хәрәкәт, намус, вак, үпкә, максат.*

**А-5.** Сыйфатлар языгыз.

*(оялчан, үпкәчел, гадел, җитди)*

Мондый кешене нинди диләр?
еш үпкәләүче — ______
һәр бәхәсне, һәр эшне дөрес хәл итүче — ______
юкка-барга шаярмаучы, көлмәүче — ______
һәрвакыт оялучы, иркен аралашмаучы — ______

## ӨСТӘМӘ ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ТЕКСТЛАР

### 1 нче текст

### Тема: Сагынырбыз сине, җәй!

#### Алма

Менә көз дә килеп җитте. Бакчаларда алмалар өлгерде.

Бакчачы бабай Чулпанга зур һәм сап-сары ранет алмасы бирде. Ул алма шундый матур, шундый тәмле һәм хуш исле иде.

Чулпан алмага бик озак сокланып карап торды. «Бу алма белән нишләргә икән? Ашаргамы, юкмы? — дип уйлады ул.— Юк, ашамыйм, бигрәк матур алма бит!»

Кичен ул алманы өстәлгә куйды да дәресләрен әзерләргә утырды. Ләкин аның бер күзе китапта, ә икенчесе алмада иде.

Иртән ул мәктәпкә китте. Мәктәптә ул шул матур алманы дусларына күрсәтте.

— Әйдә, алманы ашыйбыз,— дип кычкырдылар дуслары.

Балалар алманы, шатланып, бергә ашадылар. Шуңа күрә аларга бик күңелле булды.

*Идрис Туктардан*

**өлгерде** — поспел **сокланып** — восхищённо

### 2 нче текст

### Тема: Сагынырбыз сине, җәй!

#### Җәйге ял

Минем исемем Марат. Миңа быел җәйге каникул бигрәк тә ошады, чөнки әнием белән җәй башында беренче тапкыр Казанга бардым.

Без Казан шәһәрендә музейлар карадык, театрга да бардык. Миңа бигрәк тә Бауман урамы ошады. Анда машиналар йөрми. Ул — бик



## ТЕКСТЛАРГА БИРЕМНӘР

### 1 нче текст

### Тема: Сагынырбыз сине, җәй!

#### Алма

1. Текстның эчтәлегенә туры килгән җөмләгә + , туры килмәгән җөмләгә – билгеләре куегыз.

_____ Әнисе Чулпанга ранет алмасы бирде.
_____ Кичен Чулпан алманы ашады.
_____ Ул алманы мәктәпкә алып барды.
_____ Мәктәптә балалар алманы бергә ашадылар.
_____ Балаларга бик күңелле булды.

2. Текстта кайсы ел вакыты турында сүз бара?

а) җәй; б) яз; в) көз

3. Кирәкле сүзләрне табыгыз һәм җөмләләрне язып бетерегез.

Бакчаларда алмалар ______________________
а) үсте; б) өлгерде; в) коелды
Чулпан алмасын ______________________ куйды.
а) өстәлгә; б) кәрзингә; в) вазага
Мәктәптә ул алмасын ______________________ күрсәтте.
а) укытучыларга; б) дусларына; в) укучыларга

4. Кайсы сүзтезмә текстның исеме була ала?

а) Яхшы алма. б) Яхшы дус. в) Яхшы көн.

5. Сорауларга кыска җаваплар языгыз.

Бакчада нәрсә өлгерде? — ______________________
Чулпанга кем алма бирде? — ______________________
Алма нинди? — ______________________
Чулпан алманы кем белән ашады? — ______________________

6. Үз фикерегезне языгыз.

Чулпан нинди кыз? — ______________________
Ни өчен балаларга күңелле булды? — ______________________

# Методическое пособ ие для учителя

(5 – 11 классы)






## 1 нче ТЕМА

## САГЫНЫРБЫЗ СИНЕ, ҖӘЙ!

### 1 нче сентябрь — күңелле бәйрәм

**А 1.** Исемнәрнең Ю. к. һәм исем + сыйфат конструкциясен кабатлау.

*Кая баралар? — Мәктәпкә, бәйрәмгә, линейкага.*

*1 нче сентябрь нинди бәйрәм / көн? — Күңелле бәйрәм / шатлыклы көн.*

2. Шигырь сәнгатьле итеп уку һәм эчтәлеге буенча бәйләнешле сөйләмне үстерү өчен бирелә. Ятларга тәкъдим ителә.

3. Билгеле үткән заман формасында бирелгән фигыльләрне билгесез үткән заманның 3 нче зат күплек санына үзгәртеп әйтү.

*Балалар иртә уянганнар, сикергәннәр, шатланганнар, ... .*

4. Изафәләрне искә төшерү һәм сөйләмдә активлаштыру.

а) **Ук.** Беренче сентябрь ай башымы?

**У1.** Әйе, ... .

б) **Ук.** Спроси у Саши, 1 сентября — конец осени?

5. Исемнәрнең күплек санын һәм сингармонизм законын кабатлау.

6. *н, ң, м* хәрефләренә тәмамланучы исемнәрнең күплек санын, сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсен искә төшерү.

Укучыларның игътибарын калын хәрефләр белән бирелгән кушымчаларга юнәлтәбез.

7. *н, ң, м* хәрефләренә тәмамланучы исемнәрнең күплек санын, сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсен кабатлау.

**Ук.** Дөресме, чыннан да, сез килешәсезме? Сентябрь көз аемы? Сентябрьдә көннәр кыскаракмы?

8. Шигырь ярдәмендә бәйләнешле сөйләргә өйрәтү. Өй эше итеп бирергә тәкъдим ителә.



**У.** 1 нче сентябрьдә без иртә уяндык, сикереп тордык, ... .

9. *1 нче сентябрьдә* һәм *1 нче сентябрьдән* формаларын дөрес куллану. Күнегүдә *а* һәм *б* пунктларында җөмләләрнең бирелү тәртибе туры килми, шуңа күрә укучылар өчен авыр җөмләләрне берничә тапкыр парлап укыйбыз. Русча-татарча вариантын берничә тапкыр парлап әйткәннән соң, ныгыту күнегүләре эшлибез. Укытучы күнегүдәге җөмләләрне бирә, укучылар тиешле вариантны әйтәләр.

**Ук.** Яңа фәннәр өйрәнәбез.

**У.** Беренче сентябрьдән.

**Ук.** Җәйге каникул тәмамлана.

**У.** Беренче сентябрьдә.

10. 9 нчы күнегүдәге җөмләләрне мәгънә буенча икегә бүлеп уку. Һәр укучы үзе турында әйтә.

11. Актив кулланышка кертү өчен бирелә. Алдагы дәресләрдә мөмкин булган саен туры килгән ситуацияләрдә кулланабыз.

12. *Кем өчен?* сөйләм үрнәген ныгыту. 9 нчы күнегүдәге җөмләләр белән эшләү.

а) Укытучы башта укучыларга сорау бирә, укучылар һәрберсе үзе турында сөйли.

**Ук.** Кем өчен 1 нче сентябрь күңелле / бераз күңелсез бәйрәм? Ни өчен?

**У.** 1 нче сентябрь минем өчен ... , чөнки ... .

б) Укучылар парлап эшлиләр. Укытучы, парлы эш вакытында парталар арасында йөреп, балаларның сөйләшүләрен тыңлый. Кирәк булса ярдәм итә.

в) Парлы эш тәмамланганнан соң, һәр пардагы бер укучыдан нәтиҗә ясату.

**У1.** Минем өчен 1 нче сентябрь — күңелле бәйрәм, чөнки ... .

Ә аның өчен (күршесенә күрсәтә) ... , чөнки ... .

Күнегүләрне эшләгәндә, дәреслекләр ачык, 9 нчы күнегүне укып җавап бирергә рөхсәт ителә. Күнегү материалы алдагы дәресләрдә сөйләм зарядкасында ныгытыла.

13. Бәйләнешле сөйләргә өйрәтү. 9—12 нче күнегүләрдәге материалны берләштереп сөйләү. Өй эше итеп бирергә тәкъдим ителә.

14. Дәрескә Шәүкәт Галиевнең шигырьләр җыентыгын алып килергә тәкъдим ителә.

## Беренче кисәк (1—3 нче темалар)

| Дәрес тәртибе | Дәрес темасы | Грамматик материал | Лексика | Сөйләм үрнәкләре | Әдәби әсәрләр |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **1 нче тема. Сагынырбыз сине, җәй! (21 дәрес)** | | | |
| 1 | **1 нче сентябрь — күңелле бәйрәм** (1—8 нче күнегүләр) | Сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе<br>Изафә бәйләнешле исемнәр<br>Иярчен сәбәп җөмлә | көз ае, җәй ахыры, уку елы, Белем көне, буш вакыт, күрше, ку-нак, фән, өлкән, иртә | 1 нче сентябрь — уку елының башы. Август — җәй ае, шуңа көннәр җылырак. | *М. Әхмәтга-лиев.* Беренче көн |
| 2 | **1 нче сен-тябрь — күңелле бәйрәм** (9—13 нче күнегүләр) | Бәйлек *(белән)*<br>Бәйлек *(өчен)*<br>Иярчен сәбәп җөмлә | тәмамлана, таныша, очраша, өйрәнә, әзерли, башлана | 1 нче сентябрьдә кемнәр белән очрашасыз?<br>Кем өчен күңелле бәйрәм?<br>Минем / синең / аның өчен. Минем өчен бе-раз күңелсез бәйрәм.<br>1 нче сентябрьдә / 1 нче сентябрьдән нишлибез? | |
| 3 | **1 нче сен-тябрь — күңелле бәйрәм** (14—21 нче күнегүләр) | Бәйлек *(өчен)*<br>Иярчен сәбәп җөмлә | күчә, үсә | 1 нче сентябрьдә яздан көзгә күчтек.<br>Сентябрьдә без бер елга үстек.<br>1 нче сентябрь — ми-нем өчен бераз күңелсез бәйрәм, чөнки ... .<br>1 нче сентябрьдән иртәрәк торам, чөнки ... . | *Р. Бәшәр.* Бер елга үскәнмен |
| 4 | **Барыгызга да хәерле көн телим!** (1—9 нчы күнегүләр | Исемнәрнең иркәләү-кечерәйтү формасы<br>Вакыт рәвешләре | Хәерле иртә / көн / кич, әнкәм / әткәм / әбкәм / балакаем!<br>Тыныч йокы | Барысы да искечә.<br>Эшләрегез ничек?<br>Яңалыклар бармы? Сезне чын күңелдән котлыйбыз! | *Л. Лерон.* Хәерле иртә! |
| 5 | **Барыгызга да хәерле көн телим!** (10—16 нчы күнегүләр) | Зат алмашлыкларының Ю.к. белән төрләнеше<br>Вакыт рәвешләре | иртән, иртә белән, көндез, кичен, кич белән, төнлә, теләк, тели | Иртән кешеләр бер-берсенә: «Хәерле иртә!» — диләр. Әти-әниләр иртән өйдән эшкә баралар. Алар кичен эштән өйгә кай-талар. Мин сиңа тыныч йокы телим. Ул сезгә бәхет тели. Укытучыбыз безгә яхшы теләкләр тели. | |
| 6 | **Барыгызга да хәерле көн телим!** (17—22 нче күнегүләр) | *-лы/-ле, -сыз/-сез* кушым-чалары белән ясалган сыйфатлар<br>Боерык фигыльнең 2 нче зат формасы (берлек һәм күплек санда) | тәртипле, акыл-лы, әйбәт, олы-лар, өлкәннәр, уңыш, бәхет, котлый | Игътибарлы бул / булы-гыз! Тәртипсез булма / булмагыз! Хәерле юл! Хуш / Хушыгыз! | *Б. Рәхмәт.* Мәктәпкә! |

# Аудиодиски


Татарча да
яхшы бел
Аудиокушымта
I һәм II кисәкләр
6 класс


Татарча да
яхшы бел
7 класс
Аудиокушымта
I кисәк


Татарча да
яхшы бел
8 класс
Аудиокушымта


Татарча да
яхшы бел
9 класс
Аудиокушымта


Р. Р. Нигъмәтуллина
Ф. С. Фәизова
ТАТАРЧА ДА
ЯХШЫ БЕЛ
5 класс
АУДИОКУШЫМТА
БЕРЕНЧЕ КИСӘК


Р. Р. Нигъмәтуллина
Ф. С. Фәизова
ТАТАРЧА ДА
ЯХШЫ БЕЛ
5
Икенче кисәк
АУДИОКУШЫМТА
ИКЕНЧЕ КИСӘК

# Обучающие семинары для учителей








# Учимся учить






# Учимся учить





# мастер-классы автора в г. Москва






# Мастер-классы
## УЧИТЕЛЕЙ - ЭКСПЕРИМЕНТАТОРОВ












*мастер - классы* **автора**



Елабуга



Казань




Набережные Челны



Альметьевск

# Общение детей с гостями семинаров









**Республиканские конференции**
**Казань, ИРО РТ**







# Учителя-экспериментаторы делятся опытом









# Результаты экспериментальной деятельности





По линии МО и Н РТ проводится срез знаний учащихся. Значительно высокое качество знаний учащихся: 2005/2006 учебный год – 72%, 2006 /2007 учебный год – 74%, 2007/2008 учебный год - 74%.

ТАТАР ТЕЛЕ

| Класс | Кол-во уч-ся | 17.05.06 МО РТ | | 21.05.07 МО РТ | | 22.05.08 МО РТ | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Вып-ли | "4-5" | Вып-ли | "4-5" | Вып-ли | "4-5" |
| 5А | 25 | 21 | 15-72% | | | | |
| 6А | 24 | | | 23 | 17-74% | | |
| 7А | 22 | | | | | 23 | 74% |





**Выводы по обучению по концентрированной технологии таковы:**

1. У учащихся появился интерес к изучению татарского языка. Это проявляется на уроках, в желании участвовать во внеклассных мероприятиях. Дети стали общаться на татарском языке между собой, с учителями-предметниками.
2. Применение технологии концентрированного обучения в определённой мере способствует процессу непринуждённого вовлечения ребёнка к общению на татарском языке.
3. От учителя работа по данной технологии требует больших усилий, поскольку уроки проводятся в очень высоком темпе. Учитель должен осуществлять личностно – ориентированный подход. В то же время наличие специализированных учебников. рабочих тетрадей и аудиоматериалов, методических пособий намного облегчает работу учителя.
4. Учитель должен научить детей работать в таком темпе с первого класса. Это поможет достичь хороших результатов в работе по концентрированному методу обучения.

Но есть и недостатки: вынужденный пропуск учеником занятий может привести к серьезному отставанию. Должны соблюдаться такие условия: применять данную технологию должен педагог, обладающий способностями системного видения материала и свободного владения разными формами учебной работы, ансамблевая работа учителей (в данном случае учителей татарского, русского, иностранного языка).

Учителя продолжают работу по изучению и внедрению технологии концентрированного обучения татарского языка и литературе. Повышают свою квалификацию на постоянных курсах, организованных для учителей-экспериментаторов, на городских и республиканских семинарах.

Учитель Салахова Р.А. участвовала с результатами своего исследования по содержанию учебно-методического комплекса (авторы – Р.Р. Нигматуллина, Ф.С. Фаизова, Р.А. Юнусова) на республиканской научно-практической конференции о ходе эксперимента, на курсах учителей-экспериментаторов.

Опыт работы по этому направлению представлен на городском семинаре заместителей директоров и учителей татарского языка и литературы «Современные педагогические технологии обучения татарскому языку» в 2006 году. 21 февраля 2007 года на республиканском семинаре с участием слушателей курсов учителей татарского языка и литературы при ИРО РТ по теме «Модернизация современного содержания в преподавании татарского языка и литературы русскоязычным учащимся» учителями-экспериментаторами были даны уроки. Уроки получили высокую оценку. Была отмечена активность и заинтересованность учащихся в изучении языка, умение учителя за короткий период времени сформировать прочные умения и навыки речевого общения. Учитель и ученики общались только на татарском языке. Атмосфера на уроке была самой доброжелательной и располагала к обмену мнениями и получению новых знаний.





**Для сравнения посмотрим показатели качества знаний других школ района, ненаходящихся в эксперименте:**

**Показатель качества знаний учащихся 5-го класса Бирюлинской средней школы на 2005-2006 уч. г.**



**Показатель качества знаний учащихся 5-го класса Куркачинской средней школы на 2005-2006 уч. г.**





**Показатель качества знаний по татарскому языку на 2005-2006 уч. г. в целом по району**



**За год обучения в шестом классе мы добились следующих результатов:**

**Показатель качества знаний в экспериментальном классе по итогам 6-го класса (2006-2007 уч. г).**



**Для сравнения посмотрим показатели качества знаний других школ района, ненаходящихся в эксперименте:**

# Ведение мониторинга












# ОБОБЩЕНИЕ ОПЫТА



# Критерии оценки УМК“Татарча да яхшы бел”

**«Татарча да яхшы бел» укыту-методик комплексының беренче кисәген бәяләү**

**Казан, 13.02.07**

| Т/с | Бәяләү критерийләре | «5» | «4» | «3» | «2» | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | «Татарча да яхшы бел» ул - УМК: комплексның һәр берәмлеге бер бөтеннне тәшкил итүче, тыгыз бәйләнештәге, бер-берсен тулыландыручы, укучы һәм укытучы өчен белем чыганагы | | | | | |
| | - программа<br>- дәреслек<br>- методик кулланма<br>- эш дәфтәре<br>- аудио материал<br>- контроль эш өчен<br>- махсус дәфтәр | | | | | |
| 2. | Дәреслекнең эчтәлеге: | | | | | |
| | -темадагы сөйләм материалының логик эзлеклелектә бирелү дәрәҗәсе<br>- сөйләм материалын үзләштерүнең диалектик логика принцибына корылу дәрәҗәсе<br>- сөйләм материалының һәм аралашу ситуацияләренең яшь үзенчәлекләренә туры килүе<br>- сөйләм материалының аңлаешлы (доступность) булуы<br>- грамматик материалның лексика белән эзлекле бәйләнеше<br>- грамматик материалны ныгыту күнегүләренең эзлеклелеге һәм үзара бәйләнеше<br>- фәннилек (фәнни мәгълүмат салынган булу)<br>- предметара бәйләнеш салынган<br>- сөйләм | | | | | |
| | материалының күләме, чамаланышы (дозировка)<br>- компьютер техникасын куллану мөмкинчелеге салынган (контроль, диагностика үткәрү максатында) | | | | | |
| 3. | Дәреслек эчтәлегенә укучының иҗади фикер үсешен формалаштыруга юнәлтелгән материал салынган (үзләштерелгән конструкцияләр аша сөйләмгә, теләсә нинди контекстка һәм лексик тематикага күчү мөмкинчелеген тәэмин итә): | | | | | |
| | а) проблеманы аерып ала һәм куя белү күнекмәсе үсеше өчен<br>б) ситуацияне анализлый белү күнекмәсе үсеше өчен<br>в) куңелдән (в уме) гамәл башкара белү күнекмәсе үсеше өчен<br>г) модельләштерүгә сәләтлелек белү күнекмәсе үсеше өчен<br>д) рефлексиягә сәләтлелек белү күнекмәсе үсеше өчен | | | | | |
| 4. | Дәреслеккә кергән текстлар һәм аларның теле | | | | | |
| | а) тексттагы мәгълүмат мавыктыргыч һәм кызыклы<br>б) теле төгәл, ачык, мәгънә төсмерләрен тоемлауга юнәлтелгән, татар теленең сөйләм үрнәге булып тора ала | | | | | |

Мәгарифне үстерү институты
милли мәгариф лабораториясе мөдире — М.Г. Мозаффарова

Авторлар төркеме җитәкчесе — Р.Р. Нигматуллина

# Отзывы родителей



**Анкета для родителей.**

1. Нравится ли Вашему ребёнку экспериментальный учебник? ______

2. Что особенно нравится? ______

3. Что не нравится? ______

4. Нравится ли рабочая тетрадь? ______

5. Какие задания или тексты особенно нравится? ______

6. Занимаясь по данному учебнику, стало ли легче Вашему ребёнку осваивать татарский язык? ______

7. Готовит ли Ваш ребёнок домашние задания самостоятельно или обращается за помощью? К кому? ______

8. Ваши пожелания авторам учебника ______







*“А вот учебные пособия в этом году - просто восторг! Я уверена, они изменять отношение к этому предмету. Учебник красочный, темы интересные,учебный материал преподносится увлекательно и в доступной форме”. (Из анкеты родителей школы №13 Вахитовского района г.Казани)*

*“Автором книги удалось вникнуть в тонкости преподавания татарского языка русским детям.” (Малышев Николай Михайлович, пос. Ново-шешминск)*

# ОТЗЫВЫ УЧАЩИХСЯ


п. Комсомолец, школа, 2006 г., Чукаевский р-к
Отзыв об уроке
татарского языка в 5 классе
(рус. группа, эксперимент)
Наш сын, Прохоров Алеша, с
удовольствием посещает эти
уроки. Особенно ему нравятся
новые учебники, рабочие тет-
ради. В прошлые годы при
подготовке домашних заданий
мы часто обращались к соседям
за помощью. А в этом году
он сам старается справить-
ся с этой задачей.
Мы, родители, полностью
согласны с этим нововведе-
нием. Желаем творческих
успехов учительнице Гали-
мовой И. И.
Родители Прохоровы Алеши.


Я ученик 5ª класса г. Буинска
Ефремов Владислав. Мне очень нравит-
ся учебник татарского языка. По-
тому что в этом учебнике есть раз-
ные сказки, стихи, рассказы. Ещё мне нра-
вится тетрадь по татарскому язы-
ку. Потому что там разные задания,
тесты. Ещё на уроке татарского язы-
ка есть аудио записи. Мы повторяем за
диктором. В том году на уроке татар-
ского языка не было: таких тетрадей,
книг и аудио записей. В том году мы
писали в обыкновенных тетрадях.
А в этом году мы писали в красоч-
ных тетрадях. Ещё мы учили много
новых слов и правил. Мы учили песни
на татарском языке. Мне очень
нравится татарский язык.


Я Ежов Стефан Александрович. Учусь в 5ª классе
г. Буинске школе № 5. Мне понравилась эта
замечательная книга, потому что там много
рисунков много сказок, текстов. Там на ва...
страницах рисунки мне бы тоже хотел...
рисовать такие красивые рисунки. Что мы изуча...
надо будет в старших классах. Например на послед-
них страницах слова мы их уже выучили. ...
я начал понимать на татарском языке лучше че...
на русском языке, вот поэтому надо изучать татар...
тел. Эта книга называется Татарча да яхш...
бел. Мы уже все 17 тем прошли например
Туган көнем килегез, Эрле буру җиңүеме, Эр...
башы матур чагы, Һөнәрләр белдүе тәэзтә д...
бел, Язкиле, Язкөлә. И все запомнили вот
почему мне нравится эта книга. Изучали
три книги. Мы читали текст Бишнә Бик...
чәнтәвдан, Фәниса Эрулина, Шаукат
галиева. Мы даже учили Рэми Эхмәтҗан текст
учили. Например Сабантуй или иң күңелле ча...

«В начальных классах я мало понимала по-татарски, не могла составлять предложения. А теперь я почти научилась разговаривать по-татарски. Дома я слушаю по телевизору песни и перевожу их.»
(Рыжикова Алина, Урсалинская ср. школа Альметьевского района)

# *Обмен опытом*
































# СМИ о нас




«Шәһри Чаллы»




"Мәгариф"



## Эксперимент шартларында яңача укыту

2005-2006 уку елында ТР Мәгариф министрлыгы боерыгы нигезендә 5 нче сыйныфларның рус төркемнәрендә татар телен концентрик технологияләр кулланып укыту буенча экспериментал эш башланган иде. Дәреслекләрне Чаллы укытучысы Р.Р.Нигъмәтуллина җитәкчелегендә Чаллы һәм Казан мөгаллимнәре иҗади төркеме төзегән. Узган елның сентябреннән республика буенча 86 мәктәпнең 120 татар теле һәм әдәбияты укытучысы яңача укытуны башлап җибәрде. Алар арасында калабызның 17 нче мәктәбе укытучылары Н.Ж.Кашапова, Р.М.Махиянова, Урсалы урта мәктәбеннән И.Ә.Талипова да үз көчләрен сынап карарга булды. Экспериментның беренче елы тәмамланды. Укытучыларның фикерләре нидән гыйбарәт икән?

Н.Кашапова:

- Экспериментка бераз шикләнеп алынган идек, ләкин дәреслекләрне күргәч, аудиотасмаларны, методик кулланмаларны алгач, бик теләп эшли башладык. Концентрик технология нигезендә коммуникатив методика ята. Укытучының төп бурычы - рус баласын татар телендә аралашырга җәлеп итү. Дәреслекләрнең системалы һәм проблемалы күнегүләргә корылып төзелүе баланың мөстәкыйльлеген, логик фикерләү сәләтен, уйлау эшчәнлеген баетырга мөмкинлек бирә. Укучылар бер-берсе һәм укытучы белән аралашырга, төркемнәрдә эшләргә, үз фикерләрен дәлилли белергә өйрәнделәр. Ә эш дәфтәрләрендәге күнегүләр дәреслек нигезендә алган белемнәрне ныгыту, кабатлау өчен хәлиткеч ярдәмлек. Укучылар бик теләп контроль эшләр, тестлар, иҗади проектлар башкардылар.

И.Талипова:

- Уку елы башында ата-аналар арасында аңлату эше алып бардык. 4 еллык укыту программасы белән таныштыргач, фәннәрнең, дәресләр саны кимемәвен белгәч, алар бу төр укытуга ризалаштылар. Беренче айдан ук укучылар зур теләк белән татар телен өйрәнә башлады, үз көчләренә ышанычлары да артты. Дәреслек авторы төзегән контроль эшләрнең гомуми сыйфаты 70 процент булды. Балалар һәркем белән аңгәмә алып барырга өйрәнде. Минемчә, татар телен үзләштерүнең беренче этабы яхшы үтте.

Р.Махиянова:

- Дәреслек укучыны шәхес буларак тәрбияләүдә зур ярдәмлек булды. Мәгариф идарәсе, мәктәп җитәкчеләре киракле әсбаплар, техник чаралар белән тәэмин итте. Аларга рәхмәтебез зур. Киләчәктә экспериментны тормышка ашыруда тагын да күбрәк мәктәпләр катнашыр дип ышанабыз.

Л.САРАЧЕВА,
мәгариф идарәсенең әйдәп баручы белгече.



Татарча да яхшы бел...

## Эксперимент шартларында яңача укыту

ТРның Мәгариф һәм фән министрлыгы карары нигезендә 2005 елның 1 сентябреннән республикабызның 86 мәктәбендә татар һәм чит телләрне концентрик технологиягә нигезләнеп укыту кабул ителде. Программа һәм дәреслекләрнең авторы - Чаллы мөгаллимәсе Р.Р.Нигъмәтуллина үзенең ярдәмчеләре белән 1 елга 4 дәреслек һәм 4 эш дәфтәре тәкъдим итте, чирек саен эксперимента катнашучыларның белемен арттыру өстендә эш башлап җибәрде.

Безнең Әлмәттән 17 нче рус-татар һәм Урсалы мәктәпләре әлеге экспериментта үз көчләрен сынап карарга теләк белдерделәр. Ата-аналар җыелышында бу алым белән укытуның төп максаты

"Әлмәт таңнары"




«Биектау хәбәрләре»


16.04.05

Татарча да яхшы бел...

Миллэтемэ эйтер сузем бар

Соңгы елларда шәһәребез мәгарифе чын мәгънәсендә экспериментal мәйданчыкка әверелде. Яңалыкларның уңдырышлы туфракка төшеп, нәтиҗәле генә тамырланып киткәннәре дә байтак. Быелгы уку елыннан рус телле балаларга татар телен һәм чит телләрне укыту буенча янә бер эксперимент башланды.

# Тел өйрәтү җиңел эш түгел

“Шәһри Чаллы”


Алабуга нуры 4

УКУ ЙОРТЛАРЫНДА

# Эксперимент уңай нәтиҗә бирә

“Алабуга нуры”


...Һәр халык үзенең китабы янына чакырып китерелер. (Коръән сүзе)

Мәгърифәт плюс

«Мәгариф»

ГАЗЕТА ЭЧЕНДӘ ГАЗЕТА № 25 Август, 2005

ТӨП БАШЫ

# АДЫМ-АДЫМ ТАТАРЧА

*Сәхифәбезнең кунагы — Рузалия Нигъмәтуллина. Кем ул? Ни өчен бүген аны газетабыз түренә чакырдык? Хәер, сүзне үз тәртибе белән башлыйк әле.*

“Мәгърифәт”



alnur 5 @ mail.ru "Алабуга нуры" Жомга, 22 август, 2008 №101-102 (11740-41)

ФӘҺЕМЛЕ БАЛАЛАР

# ТАТАР КЫЗЫ БУЛАСЫМ КИЛӘ!

Марина шәһәрнең 2 нче ур-
а мәктәбендә рус телле ба-
алаларга татар теле укыту бу-
нча эксперимент сыйныф-
а укый. Исегезгә төшерә-
ез, эксперимент 2005-2006
у елында республика кү-
әмендә 86 мәктәптә баш-
анган иде. Биш еллык про-
тның авторы – республи-
буенча экспериментның
итәкчесе, мәгарифне үсте-
институты ректоры Рәис
әйхелисламов. Әлеге про-
т нигезендә тел, чит илләр-
әге кебек, баскычлап өйрә-
елә. Бу сыйныфларда уку-
ы рус телле балалар татар
елен өйрәнүне кирәксез
ер эш итеп карамый, әти-
ниләренең дә тел өйрәнү-
мөнәсәбәте яхшы.
ыел экспериментның өчен-
е елы тәмамлануга багыш-
анган республика фәнни-
рактик семинары вакытын-
а "Сәләт" лагере директо-
ы Җәүдәт Сөләйман белән
еспубликадагы һәр экспе-
имент классыннан татар
елен яратып өйрәнгән бер
кучыны җәй көне лагерьда
п иттерү турында килешү
эзелә. Бу укучыларга, ла-
ерьда ял итүче татар бала-
ары белән аралашып, өй-
энгәннәрен практикада ны-
ыту мөмкинлеге бирергә ти-
ш була. Маринаның да та-
р лагерена ял итәргә ба-
хыялы тормышка аша.
арина 17 июльдән 3 ав-
тка кадәр "Сәләт" лаге-
нда ял итә. Яшьләр 9 төр-
мгә бүленеп яши, башка
ллардан аермалы буларак,
ралары͏нда республиканың
ксперимент классларыннан
илгән 15 җиденче класс уку-
ысы да була. Һәр көн та-
ар, инглиз һәм испан тел-
әре, шәхес психологиясе,
раторлык сәләте кебек дә-
есләр керә, һәр төркемгә
ерым тематик биремнәр
ишәргә тәкъдим ителә, да-

тырыла. Сәлкешләрнең һәр-
берсенә зәңгәр галстук һәм
махсус лагерь билгесе төше-
релгән сары футболкалар
бүләк ителә. Әлбәттә, ла-
герьда үзара аралашу укы-
тучылар, әйдаманнар белән
аралашу белән генә үрелеп
бармый, яшьләр арасында
яхшы билгеле булган шә-
хесләр белән очрашулар
аеруча күңелле үтә. Өчен-
че смена вакытында "Сәләт"

Автор фотосы

тә Нурбәк һәм Илназ Са-
фиуллин кунак булып китә.
Татар эстрадасының яшь
җырчысы Илназ белән бер-
гәләшеп учак тирәли утырып
гитарага кушылып җырлап
утыру Маринаның да күңе-
лендә якты хатирәләр кал-
дырган. Алай да, иң истә
калган көн дип, ул сменаны
ачу көнен атый: "Лагерь буй-
лап йөгерешеп футболкалар
эзләп йөргәннәр әле дә ис-
тә, нинди генә биремнәр
башкарырга киртәләр үтәр-

үзе ни тора! Русча, хәтта та-
тарча сөйләшә белүче аме-
риканнар белән очрашу ту-
рында әйтәсе дә юк...
Бер сүз белән әйткәндә, Ма-
рина "Сәләт" лагерена ба-
рып кайта алуы белән бик
бәхетле. Анда киләсе елга да
барырга хыяллана. Кызның
әнисе сүзләренчә, Марина-
ның моңа кадәр кая да бул-
са бару теләге булмаган,
буш вакытын ул күбрәк өй-
дә уздырырга, әбисе янына
авылга кайтырга яраткан.
-Нишләттегез сез минем кы-
зымны?.. Татар лагерена
шулкадәр теләп китте дә ан-
нан шундый канәгать булып
кайтты. Мин моңа бик шат, -
ди Маринаның әнисе. Шу-
нысын да билгеләп үтәргә
кирәк, юллама бәясе 7700
сум булса да, Титовалар аны
нибары 3 мең сумга сатып
алган. Мондый ташламалар
портфолиолары бик яхшы
яшьләргә генә ясала. Киләсе

-Соңгы төнне сәлкешләрнең
күбесе йокысыз үткәрде.
Дискәтүк тә төнге өчкә кадәр
дәвам итте. Мин исә, сәла-
мәтлегем бераз какшаган-
лыктан, йокламыйча булды-
ра алмый идем. Ә иртән то-
руга нәрсә дип беләсез? Бө-
тен битемне теш пастасы бе-
лән буяп чыкканнар! - дип ур-
таклаша Марина истәлекл ә-
ре белән.
"Сәләткә" барып кайтканнан
соң, татар телендә тизрәк
сөйләшә башладым, никадә-
лы яңа дуслар таптым, мин
бик бәхетле, - ди ул.
2 нче мәктәпнең татар теле
укытучысы Раушания Хә-
лиуллина: "Сыйныфыбыз-
да татарча матур итеп сөй-
ләшә белүче укучылар бер
Марина гына түгел әле", -
дип куандырды. Татар те-
ле юкка чыга, беркемгә дә
кирәге калмый, дип куркы-
талар, баксаң, башка мил-
ләт кешеләре дә телебез-






ТАТАРЧА ДА ЯХШЫ БЕЛ
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ЭШ ДӘФТӘРЕ
5 класс
ИКЕНЧЕ КИСӘК
"МӘГАРИФ" НӘШРИЯТЫ

ТАТАРЧА ДА ЯХШЫ БЕЛ
5 класс
Sprechen Sie Deutsch?
Татарча да яхшы бел
6 класс
Татарча да яхшы бел
Аудиокушымта
I кисәк
7 класс

ТАТАРЧА ДА ЯХШЫ БЕЛ
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ЭШ ДӘФТӘРЕ
6 класс
ИКЕНЧЕ КИСӘК
"МӘГАРИФ" НӘШРИЯТЫ

ТАТАРЧА ДА ЯХШЫ БЕЛ
7 класс

ТАТАРЧА ДА ЯХШЫ БЕЛ
8 класс

ТАТАРЧА ДА ЯХШЫ БЕЛ
9 класс